**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы**
**Яңа Элмәле авыл җирлеге гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге составына керүче Иске Элмәле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**№1** **27.10.2023 ел**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Чирмешән муниципаль районының Яңа Элмәле авыл җирлеге Уставының 22 ст., Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Яңа Элмәле авыл җирлеге Советының 2019 елның 11 июнендәге «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль район Советының 2018 елның 24 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Яңа Элмәле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын уздыруга әзерлек тәртибе турында» гы нигезләмәне раслау турында» №94 карарына үзгәрешләр кертү хакында» №132 карары нигезендә 2023 елның 27 октябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены карары түбәндәге мәсьәләләр буенча төзелде:

2024 елда муниципаль районның Яңа Элмәле авыл җирлегенең Иске Элмәле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 800 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк кешеләрдән, күп балалы аналардан, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан тыш һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- җәйге һәм кышкы чорда юлларны төзекләндерүгә, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә чыгымнар (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдлау, кышкы чорда урамнарны кардан чистартуга, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, элмә һәм тагылма җиһазлар сатып алуга, тракторчыга хезмәт күрсәтүгә түләү) Иске Элмәле торак пунктында;
- Иске Элмәле торак пунктында урамнарны яктырту, монтажлау, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Яңа Элмәле авыл җирлегендә урам-юл челтәрен төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, вак таш сатып алу;
- мотопомпа сатып алу
- җиңел автомобиль өчен прицеп сатып алу
- генератор сатып алу

- Яңа Элмәле авыл җирлегендә яшәүчеләргә һәм аларның мөлкәтенә куркыныч тудыручы агачларны кисү (хезмәт өчен түләү һәм югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле кораллар сатып алу).

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 410 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 223 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен гражданнар җыенында 223 катнашучы тавыш бирде; «ЮК» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә халык җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлегенең Иске Элмәле торак пунктында халык җыены булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын дип таныргa.

2. Киләсе мәсьәлә буенча:

2024 елда муниципаль районның Яңа Элмәле авыл җирлегенең Иске Элмәле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 800 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк кешеләрдән, күп балалы аналардан, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан тыш һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- җәйге һәм кышкы чорда юлларны төзекләндерүгә, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә чыгымнар (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдлау, кышкы чорда урамнарны кардан чистартуга, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, элмә һәм тагылма җиһазлар сатып алуга, тракторчыга хезмәт күрсәтүгә түләү) Иске Элмәле торак пунктында;

- Иске Элмәле торак пунктында урамнарны яктырту, монтажлау, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- Яңа Элмәле авыл җирлегендә урам-юл челтәрен төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, вак таш сатып алу;

- мотопомпа сатып алу

- җиңел автомобиль өчен прицеп сатып алу

- генератор сатып алу

- Яңа Элмәле авыл җирлегендә яшәүчеләргә һәм аларның мөлкәтенә куркыныч тудыручы агачларны кисү (хезмәт өчен түләү һәм югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле кораллар сатып алу) – карар кабул ителгән дип таныргa.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Иске Элмәле авылы, Үзәк урамы, 10. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы рәсми сайтында Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче**
**Яңа Элмәле авыл җирлеге башлыгы** **И.М. Җамалтдинов**